# Сәхәбәләрнең фазыйләтләре һәм хаклары

فضل الصحابة وحقوقهم

اللغة التتارية

ALSARHAAN.COM

وَالسَّابِقُونَ الْأَوَّلُونَ مِنَ الْمُهَاجِرِينَ وَالْأَنْصَارِ وَالَّذِينَ اتَّبَعُوهُمْ بِإِحْسَانٍ رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُمْ وَرَضُوا عَنْهُ وَأَعَدَّ لَهُمْ جَنَّاتٍ تَجْرِي تَحْتَهَا الْأَنْهَارُ خَالِدِينَ فِيهَا أَبَدًا ۚ ذَٰلِكَ الْفَوْزُ الْعَظِيمُ

**«Иң беренчеләрдән булучы мөһаҗирләр, һәм яхшылыкта мөһаҗирләргә иярүче ансарлар, алардан Аллаһ разый булды һәм алар Аллаһтан разый булдылар. Һәм ул аларга аяк асларыннан елгалар ага торган җәннәтләр әзерләде, алар анда мәңге калырлар. һәм бу - бик бөек уңыш».**

الصحابة خير هذه الأمة نفوسًا وابرها قلوباً وأعمقها علماً وأقلها تكلفًا. وهم أعلم الأمة بمراد الله تعالى في كتابه. ومراد النبي صلى الله عليه وسلم في سُنته.

**Сәхәбәләр шушы өммәттән күңелләре белән иң яхшылары, йөрәкләре белән игелеклеләре, иң тирән гыйлем ияләре һәм төрле кыламышлардан һәм күз буяудан иң ерак булучылары. Һәм алар Аллаһ Үз китабында һәм Пәйгамбәребез ﷺ үзенең сөннәтендә нәрсә әйтергә теләгәннәрен иң белүчеләр.**

وأوفق الناس عملا بالكتاب والسنة. وأكملهم نصحا وأبعدهم عن البدع والأهواء.

Сәхәбәләр кешеләр арасыннан Коръән һәм сөннәт буенча кылган гамәлләре белән иң яхшылары. Ихлас мөнәсәбәттә иң төгәлләре, һәм бидәгать һәм һәвәслектән иң ерак торучылары.

ومن حقهم علينا، الاعتراف بما ثبت من فضلهم واقرار ما صح من فضائلهم. ومحبتهم بالقلب والترضي عنهم باللسان لما لهم من السابقة ولما أسدوه من المعروف والإحسان.

Һәм сәхәбәләрнең безгә карата булган хакларыннан:

–алар турында исбат ителгән фазыйләтләрне тану һәм раслау, аларда булган нәрсәләр өчен һәм алар кылган яхшылыклар һәм изгелекләр өчен йөрәк белән аларны ярату һәм тел белән алардан риза булу;

التلقي عنهم وحسن التأسي بهم. مع سلامة القلوب من بغضهم أو الحقد على أحد منهم.

– аларга карата нәфрәттән һәм ачудан пакь, чиста йөрәк белән алардан кабул итү һәм аларны үрнәк итеп алу;

اعتقاد حرمة سبهم ولعنهم أشد حرمة. ففي ذلك معارضة لما جاء في القرآن من تزكيتهم والثناء عليهم، ووعدهم بالحسنى.

– аларны сүгү һәм ләгънәт кылу нык тыелган икәнлегенә ышану;

Чөнки аларны сүгү – аларга карата мәдхия, мактау, Җәннәт вәгдә ителеп язылган Коръәнгә капма-каршы булып тора.

وفيه سوء أدب مع النبي صلى الله عليه وسلم الذي أمر بحبهم ونهى عن سبهم.

Һәм шулай ук аларны сүгүдә һәм ләгънәт кылуда Пәйгамбәребезгә ﷺ карата начар адәп бар, ул бит аларны яратырга әмер итте һәм аларны сүгүдән тыйды.

فقال: لا تسبوا أصحابي والذي نفسي بيده لو أنفق أحدكم ملء أُحدٍ ذهبًا ما أدرك مُدَّ أحدهم أو نصيفه.

Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: "Минем сәхәбәләремне сүкмәгез, минем җаным кулында булган Аллаһ белән ант итәм, әгәр сездән берәрегез Ухуд тавы шикелле күләмдә алтын сарыф итсә, ике уч я инде бер уч күләмендә сарыф иткән сәхәбәнең әҗерен ала алмас".

الكفّ عن الخوض فيما شجر بينهم واعتقاد أنهم مجتهدون مأجورون.

Шулай ук сәхәбәләрнең безгә карата булган хакларыннан булып тора:

– алар арасында булган капма каршылыклардан ерак булу;

– аланың Аллаһ юлында тырышлык күрсәтүләренә һәм әҗер-савап ияләре булуларына инану;

له اجران والمخطئ له أجر. وخطؤه مغفور لاجتهاده.
– Тырышканына ике әпҗер-савап, ә ялгышканына бер әҗер-савап булуы, һәм тырышлыгы аркасында аның хатасы гафу ителүенә ышану;

الحذر من نشر ما قد يُنسَب إلى أحدهم من مساوئ.
– алар турында әйтелгән хата-кимчелекләрне таратуда сак булу;

فإنّ جملته كذب مختلق. وما ثبت عنهم في ذلك.فهو يسير مغمورٌ في بحر حسناتهم.
Мондый гамәл аларга карата ялганлау. Һәм алар турында хаталары исбатланган булса да, алар кылган яхшылыклар белән чагыштырганда бу хата диңгезендәге нокта сыман.

اعتقاد تفاوتهم في الفضل وكلهم فضلاء.
– аларның дәрәҗәләре белән башкалардан аерылып торулары һәм барысының да хөрмәткә лаеклы булуларына ышану;

فأفضلهم الخلفاء الراشدون ثم العشرة المبشرون بالجنة.
ثم أهل بدر ثم أهل بيعة الرضوان وهكذا.

Һәм алардан иң яхшылары – ул туры юлда булган дүрт халифә, алардан соң Җәннәт белән сөендерелгән ун сәхәбә, шуннан соң Бәдер сугышы әһелләре, алардан соң канәгатьлек анты биргәннәре һәм башкалар.

{لَا يَسْتَوِي مِنكُم مَّنْ أَنفَقَ مِن قَبْلِ الْفَتْحِ وَقَاتَلَ ۚ أُولَٰئِكَ أَعْظَمُ دَرَجَةً مِّنَ الَّذِينَ أَنفَقُوا مِن بَعْدُ وَقَاتَلُوا ۚ وَكُلًّا وَعَدَ اللَّهُ الْحُسْنَىٰ ۚ وَاللَّهُ بِمَا تَعْمَلُونَ خَبِيرٌ}.

Бөек Раббыбыз әйтте:

«Сезләрдән Мәккәне ачыр алдыннан малын Аллаһ юлына биргән һәм Аллаһ юлында сугыш кылган кеше бертигез булмас, Мәккәне алганнан соң малын биргән һәм Аллаһ юлыңда сугыш кылган кешедән алар дәрәҗәдә олугърактыр. Аларның һәрберсенә дә Аллаһ Җәннәтне вәгъдә кылды, Ул – Аллаһ сезнең кылган эшләрегездән хәбәрдардер».

الدعاء لهم والترحم عليهم وطلب المغفرة لهم.
– Һәм түбәндәге сүзләргә нигезләнеп, алар өчен дога кылу, хөрмәт итү, һәм Аллаһтан алар өчен гафу сорау.

عملا من قوله تعلى :
«وَالَّذِينَ جَاءُوا مِن بَعْدِهِمْ يَقُولُونَ رَبَّنَا اغْفِرْ لَنَا وَلِإِخْوَانِنَا الَّذِينَ سَبَقُونَا بِالْإِيمَانِ وَلَا تَجْعَلْ فِي قُلُوبِنَا غِلًّا لِّلَّذِينَ آمَنُوا رَبَّنَا إِنَّكَ رَءُوفٌ رَّحِيمٌ»
Аллаһ әйтте:

«Алардан соң килечүләр әйтерләр: “Ий Раббыбыз, безне һәм бездән әүвәл иман китерүче дин кардәшләребезне дә гафу ит, һәм безнең күңелләребездә иман китергән кешеләргә карата ачу урнаштырма, ий Раббыбыз, Син, әлбәттә, Йомшак һәм Рәхимле!”».